«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча 2024 елның 16 ноябрендәге гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар)

БЕРКЕТМӘСЕ

Үткәрү урыны: Чарлы авылы, Яшьләр ур., 10 нче йорт
Үткәрү датасы: 16.11.2024 ел
Үткәрү вакыты: 14 сәгать 00 мин

Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрүгә нигез: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Чарлы авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 15 октябрендәге 4 номерлы карары.

Гавами тыңлауларда рәислек итүче:
Козлов Э.Н. – Чарлы авыл җирлеге башлыгы

Катнаштылар:
Мөбәрәкшин Р.И. – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге архитекторы
Закиров И.Г. – Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе

Гавами тыңлауларда (иҗтимагый фикер алышуларда) катнашучылар – 21 кеше, шул исәптән хезмәт һәм оешма җитәкчеләре.

Көн тәртибе: «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча фикер алышу

Тыңланды:
Козлов Э.Н. утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проект буенча РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Чарлы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Чарлы авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы карары нигезендә гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе турында мәгълүмат бирде.

Беркетмәне рәсмиләштерү һәм кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен бертавыштан түбәндәге составта гавами тыңлаулар секретариаты сайланды:
- Чапуринов А.Н. – Чарлы авыл җирлеге Советы депутаты;
– Багаманов Л.А. – Чарлы авыл җирлеге Советы депутаты;
-Муллахметова Л.З.. – Чарлы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре.

Алып бару тәртибе буенча:

Гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) тәнәфессез үткәрергә һәм бер сәгать эчендә тәмамларга.

Докладчыга сораулар юк иде.

Э.Н.Козлов үз чыгышында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы нигезендә, гамәлдәге законнар нигезендә гавами тыңлаулар процедурасын

үткәрергә кирәклеге турында хәбәр итте. Үзенең чыгышында ул тыңлаучыларны тәкъдим ителә торган «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проектның төп эчтәлеге белән таныштырды.

Ул үз чыгышында аңлатканча, «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проектында 727 кв. м мәйданлы 16:23:180401:356 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт каралган, урнашкан адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Чарлы авыл җирлеге, Татар Толлысы ав., Яшьләр ур., 2 – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Чарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонада (ОД1 )«Фельдшер-акушерлык пунктлары, шул исәптән модульле пунктлар»

Докладчыга сораулар юк иде.

Рәислек итүче катнашучыларны гавами тыңлауларга нәтиҗәсе проекты белән таныштырды.

Гавами тыңлауларда катнашучылар бертавыштан карар кылдылар:

1. «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча гавами тыңлауларны узган дип исәпләргә.
2. «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проектны тәкъдим ителгән документлар нигезендә хупларга.
3. ТР Кукмара муниципаль районының Чарлы авыл җирлеге башлыгы Э.Н.Козловка «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проектны килештерергә һәм «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә раслау өчен Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына җибәрергә киңәш итәргә.
4. 3. Гавами тыңлаулар буенча йомгакны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) ябык дип белдерелде.

Рәислек итүче Козлов Э.Н.